ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

02.02.2026 г. Казань № 10-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2025 елның 29 гыйнварындагы 10-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2025 елның 29 гыйнварындагы 10-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Хокук бүлегенә Р.Ф.Шәяхмәтовка әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Г.Г.Мотыйгуллинны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсе башлыгы Т.М. Галиев

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2025 елның 29 гыйнварындагы 10-од номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2026 елның 2 февралендәге 10-од номерлы боерыгы редакциясендә)

# Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен (алга таба – дәүләт хезмәте) билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүче: эт хуҗасы – эткә милек хокукында яисә башка закон нигезендә ия булган физик зат (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүченең мәнфәгатьләрен законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тәкъдим итәргә мөмкин.

Әлеге Регламент нигезләмәләре түбәндәгеләргә кагылмый:

1) хезмәт итүче хайваннарны тотуга һәм алардан файдалануга;

2) күрү сәләте буенча инвалидларны озата йөрүче этләрне йөртүгә.

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүченең Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы), шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә.

Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) Бердәм порталдагы, шулай ук Республика порталындагы шәхси кабинетында дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында статуслар урнаштырыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе, мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйсез рәвештә, урнаштырыла.

1.4. Регламентта кулланыла торган шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

2.2.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы орган – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе (алга таба – Ветеринария идарәсе).

2.2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе карамагындагы район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре (алга таба – Ветеринария учреждениесе) күрсәтә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) этне теркәү (хуҗасы һәм аның эте турында белешмәләрне Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Мәгълүмат системасы) кертү) һәм мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында әлеге Регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән форма буенча хәбәр итү.

2) этне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрнең үзгәрүенә яисә эткә милек хокукының күчүенә бәйле рәвештә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү һәм мөрәҗәгать итүчегә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында әлеге Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән форма буенча хәбәр җибәрү;

3) әлеге Регламентка 8 нче кушымтадагы форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

Дәүләт хезмәте Ветеринария учреждениесенең Татарстан Республикасы территориясендә тотыла торган эт һәм аның хуҗасы турында мәгълүматны мәгълүмат системасына кертүен үз эченә ала.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә сайланган ысул нигезендә җибәрелә:

1) почта аша кәгазь чыганакта;

2) электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә;

3) Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына яисә Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына.

2.3.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторларын күрсәтеп, шушы Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты.

2.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь срогы, мөрәҗәгать итүченең категориясенә (билгеләренә) бәйсез рәвештә, түбәндәгечә:

1) әгәр гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүченең вәкиле тарафыннан шәхсән тапшырылса, Ветеринария учреждениесе тарафыннан гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән алып өч эш көненнән дә

артмаган вакытта күрсәтелә.

2) әгәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче яисә мөрәҗәгать итүченең вәкиле тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинет яисә Республика порталындагы шәхси кабинет аша тапшырылса, Ветеринария учреждениесе тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең Бердәм порталда яисә Республика порталындагы шәхси кабинетында чагылдырылган номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелгән көннән алып өч эш көненнән дә артмаган вакытта күрсәтелә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

2.5.1. Дәүләт хезмәте Ветеринария учреждениесе тарафыннан түләүсез күрсәтелә.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.7. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын теркәүгә алу чоры.

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

2.7.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.7.3. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр Ветеринария идарәсенең рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлекләр булганда) һәм Республика порталында урнаштырылган.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану һәм сыйфат күрсәткечләре Ветеринария идарәсенең рәсми сайтында, Бердәм порталда (техник мөмкинлекләр булганда) һәм Республика порталында урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.10.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Мәгълүмат системасы кулланыла.

2.10.3. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.10.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, гариза бирүне дә кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша гамәлгә ашырылмый.

2.10.5. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

3) электрон рәвештә бирелгән гаризаны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

6) Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Ветеринария учреждениесе, шулай ук аның вазыйфаи затлары карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.10.6. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда һәм Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.10.7. Гаризаны формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) гаризаны һәм документларны күчереп алу һәм саклап калу мөмкинлеге;

2) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

3) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

4) «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итү торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль системасында (алга таба – БИАС) урнаштырылган мәгълүматлардан һәм Республика порталында, Бердәм порталда урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып, БИАС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә мөрәҗәгать итүче мәгълүматлар кертә башлаганчыга кадәр гаризаның электрон формасындагы кырларны тутыру;

5) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

6) кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гаризаларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризалар буенча – кимендә өч ай дәвамында.

2.10.8. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә гаризага гади электрон имза белән имза сала.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә Бердәм системада теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

2.10.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

Язма мөрәҗәгать буенча Ветеринария учреждениесенең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен һәм Регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне җентекле рәвештә язмача аңлатып бирә һәм законнарда билгеләнгән срок эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрә. Җаваплар мөрәҗәгать итү телендә бирелә. Мөрәҗәгать итү телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.11.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) мөстәкыйль тапшыра торган документларга һәм мәгълүматка бүлеп, һәм мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш, яисә мондый документларның булмавын күрсәтеп, әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән.

2.11.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның формасы шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) шушы Регламентның 2.11 пунктында каралган документларның тулы булмаган комплектын тапшыру;

2) гаризада һәм аңа теркәп бирелә торган документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартулар, өстәп язулар һәм төзәтмәләр булу;

3) гаризаның рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталда яисә Республика порталында гаризаның интерактив рәвешендә кырларны тулысынча яисә дөрес

тутырмау;

4) электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булу.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар формасы шушы Регламентның 9 нчы кушымтасында китерелгән.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның яисә мөрәҗәгать итүче ышанычнамә нигезендә эш итәргә вәкаләт бирмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

2) дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләр булган гариза һәм (яисә) документлар тапшыру.

2.12.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр, мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр әлеге Регламентка 4 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, Ветеринария учреждениесе мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп, хәбәр итә.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) үткәрелә торган административ процедураны, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң мөрәҗәгать итүчегә карата чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны) бүлүне күздә тоткан административ процедураны, мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатлау рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын гамәлгә ашыру каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәге административ процедуралар башкарыла:

1) мөрәҗәгать итүчене профильләштерү;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

4) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

4.1. Техник мөмкинлек булганда, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентта билгеләнгән хезмәт күрсәтү буенча аның гаризасының статусы үзгәрүе (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен күрсәтү турында), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күрсәтелгән этабында мөрәҗәгать итүче тарафыннан башкарылырга тиешле адымнар һәм гамәлләр турында санап үтелгән түбәндәге ысулларның берсе буенча хәбәр ителә:

- смс-мәгълүмат бирү юлы белән;
- Бердәм портал ярдәмендә;
- Республика порталы аша;
- башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

4.2. Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) Бердәм порталдагы, шулай ук Республика порталындагы шәхси кабинетында дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында статуслар урнаштырыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе, мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйсез рәвештә, урнаштырыла.

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Дәүләт хезмәте – Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү.

2. Бердәм портал – Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/).

3. БИАС – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы.

4. Мөрәҗәгать итүче – эткә милек хокукында яисә башка закон нигезендә ия булган эт хуҗалары, физик затлар.

5. Мәгълүмат системасы – Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

6. Микрочип – этнең тәненә кертелгән уникаль цифрлы яисә хәрефле-цифрлы идентификация номеры булган электрон маркировка чарасы.

7. КФҮ – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге.

8. Мөрәҗәгать итүченең вәкиле – Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат.

9. Документлар проектлары – дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, этне теркәү турында хәбәр проекты яисә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр проекты.

10. Регламент – Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты.

11. Республика порталы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/);

12. Техник хата – җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү.

13. Ветеринария учреждениесе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе ведомствосындагы район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре.

14. Ветеринария идарәсе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе.

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| Т/с | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе исеме | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Этне теркәү (хуҗасы һәм аның эте турында Мәгълүмат системасына кертү) һәм мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында хәбәр итү | Эткә милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булган физик зат | 1А |
| | | Законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар | 2А |
| 2 | Этне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрнең үзгәрүенә яисә эткә милек хокукының күчүенә бәйле рәвештә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү һәм мөрәҗәгать итүчегә Мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр җибәрү | Эткә милек хокукында яисә башка законлы нигездә ия булган физик зат | 1Б |
| | | Законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар | 2Б |

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

## Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| Т/с | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документлар төрләренең шифрын ачу, төркемнән документлар саны | Бирү ысулы |
|---|---|---|---|
| 1. Мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырган документлар һәм мәгълүмат | | | |
| 1.1. Этне теркәү өчен | | | |
| 1. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) | Ветеринария учреждениесе, Бердәм портал, Республика порталы |
| 2. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ күчермәсе | Ветеринария учреждениесе |
| 3. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Этк (булган очракта) милек хокукы яисә башка әйбер хокукы булуын раслый торган документ | Ветеринария учреждениесе, Бердәм портал, Республика порталы |
| 4. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Этнең фотосы (мөрәҗәгать итүче теләге буенча) | Ветеринария учреждениесе, Бердәм портал, Республика порталы |
| 5. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Эт тәненә кертелгән микрочип турында мәгълүмат булган хайван паспорты күчермәсе | Ветеринария учреждениесе, Бердәм портал, Республика порталы |
| 1.2. Этне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләр үзгәргән яки Мәгълүмат системасында булган этк милек хокукы күчкән очракта, эт хуҗасы (этк милек хокукы күчкәндә – яңа хуҗа) | | | |
| 1. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) | Ветеринария учреждениесе, Бердәм портал, Республика порталы |
| 2. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ күчермәсе | Ветеринария учреждениесе |
| 3. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Этк (булган очракта) милек хокукы яисә башка әйбер хокукы булуын раслый торган документ | Ветеринария учреждениесе, Бердәм портал, Республика |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | порталы |
| 4. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Этнең фотосы (мөрәҗәгать итүче теләге буенча) | Ветеринария учреждениесе, Бердәм портал, Республика порталы |
| 5. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Эт тәненә кертелгән микрочип турында мәгълүмат булган хайван паспорты күчермәсе | Ветеринария учреждениесе, Бердәм портал, Республика порталы |
| 2. Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документлар, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш | | | |
| 1. | Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документлар юк | | |

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| Т/с | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы | Нигезләр исемлеге |
|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | | |
| 1. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Регламентның 2.11 пунктында каралган документларның тулы булмаган комплектын тапшыру |
| 2. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Гаризада һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистарту, өстәп язу урыннары һәм төзәтмәләр булуы |
| 3. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Гаризаның рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталда яисә Республика порталында гаризаның интерактив рәвешендә кырларны тулысынча яисә дөрес тутырмау |
| 4. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы |
| Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләрнең тулы исемлеге | | |
| 1 | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган | |
| Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге: | | |
| 1. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның яисә мөрәҗәгать итүче ышанычнамә нигезендә эш итәргә вәкаләт бирмәгән затның мөрәҗәгать итүе |
| 2. | 1А, 2А, 1Б, 2Б | Дөрес булмаган һәм (яисә) каршылыклы белешмәләр булган гариза һәм (яисә) документлар тапшыру |

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Рәвеше

Җитәкче ______________________________________
(дәүләт ветеринария берләшмәсе урнашкан
______________________________________________
район яисә шәһәр исеме)

кемнән

______________________________________________
(Эт хуҗасының* Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

______________________________________________
Шәхесне таныклаучы документ*:______________
сериясе ____________ номеры ____________,
бирелгән ____________________________________
______________________________________________
(кем тарафыннан, дата)

ИНН номеры *: ________________________
Яшәү урыны буенча теркәлү*: _____________
______________________________________________
Элемтә өчен телефон номеры
эт хуҗасы: _____________________________
Электрон почта адресы:___________________

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать

Мөрәҗәгать итүегезнең максатын сайлагыз* (V тамгасын куегыз):

- ☐ Этне теркәүне (эт һәм аның хуҗасы турында мәгълүматны Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертүне) гамәлгә ашыруны сорыйм.
- ☐ Этне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрнең үзгәрүенә яки эткә милек хокукының күчүенә бәйле рәвештә Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертү өчен мәгълүмат:

| | |
|---|---|
| Хайванның биологик төре | |
| Токымы (билгеле булса) | |
| Этнең туган көне | |
| Этнең төсе (буявы) | |

| | |
|---|---|
| Этнең җенесе | |
| Маркировкалау турында белешмәләр (маркировкалау датасы, маркировкалау чарасының исеме, маркировкалау чарасының номеры, маркировкалау чарасының тасвирламасы, маркировкалау чарасын беркетү, яисә кертү, яисә салу урыны, маркировкалауны гамәлгә ашырган зат (оешма) турында белешмәләр) | |
| Этне тотуның максаты | |
| Этне тоту тибы | |
| Этне тоту урыны | |
| Эт хуҗасы турында мәгълүматлар (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм физик затның шәхси счетының иминият номеры) | |
| Ата-аналарының уникаль номеры (әгәр этнең ата-анасы Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алынган һәм билгеле булса) | |
| Дәвалау һәм профилактика чараларын үткәрү турында (әгәр билгеле булса), шул исәптән дезинфекция, дегельминтизация, дезакаризация, профилактик вакцинация турында, дару препаратларын куллану турында белешмәләр | |
| Россия Федерациясенә кертү турында мәгълүматлар (кертү датасы һәм экспортлаучы ил, Россия Федерациясенә керткәндә хайванны озата барган ветеринария документының датасы һәм номеры) - читтән кертелгән этләр өчен | |
| Нәсел кыйммәте (нәсел кыйммәте юк, нәселле, билгеләнмәгән) | |

Мин белдерүдә күрсәтелгән барлык мәгълүматның дөрес булуын раслыйм.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен әлеге гаризада күрсәтелгән яшәү урыны буенча кәгазьдә/электрон документ формасы буенча әлеге гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына җибәрүегезне сорыйм (кирәклесен ассызыкларга)

Мөрәҗәгать итүченең имзасы
Дата

«*» дип билгеләнгән кырларны тутыру мәҗбүри була

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Рәвеше

______________________________________________________________

карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Этне теркәү турында белдерү

____________________ «_____» ________ 20___ ел.
(торак пункт)

Әлеге ____________________________________________________________
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))
Сезнең токымлы эт турында мәгълүмат: ______________________________, кушаматы: ______________________________ микрочип № __________________________ Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына кертелде.

Карар кабул итүгә
вәкаләтле затның вазыйфасы

______________/____________________________
(имза) Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

Башкаручы
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

_____________________________________________
(башкаручының элемтә белешмәләре)

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Рәвеше

______________________________________________
карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына үзгәрешләр кертү турында хәбәр

____________________ «_____» _______ 20___ ел.
(торак пункт)

Әлеге ______________________________________________
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасына токымлы этккә карата үзгәрешләр кертелүе турында хәбәр ителә: ______________________, кушаматы: ______________________ микрочип № ______________________, чөнки ________________________________________.

Карар кабул итүгә
вәкаләтле затның вазыйфасы

_____________/___________________________
(имза) Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

Башкаручы
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

________________________________________
(башкаручының элемтә белешмәләре)

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

Рәвеше

_______________________________________________

карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

Кемгә: ______________________________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

______________ 20___ ел. № _________

__________________________________________ гаризасын карау нәтиҗәләре буенча

(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

___________ № ____________ аңа кушымта итеп бирелгән документлар, түбәндәге нигезләр буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1. ___________________;

2. ___________________.

Күрсәтелгән хокук бозулар бетерелгәннән соң, сез кабат вәкаләтле органга дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

Карар кабул итүгә
вәкаләтле затның вазыйфасы

_____________/__________________________

(имза) Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

Башкаручы
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

________________________________________

(башкаручының элемтә белешмәләре)

Татарстан Республикасында этләрне мәҗбүри теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта

Рәвеше

___________________________________________________________
карар кабул итүгә вәкаләтле орган исеме

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар

Кемгә: ______________________________
Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

_____________ 20___ ел. № _________

________________________________________ гаризасын карау нәтиҗәләре буенча
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
____________________________________________________________________________.
_________ ел, № _____ , дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:

1. __________________;
2. __________________;

Карар кабул итүгә
вәкаләтле затның вазыйфасы

____________/________________________
(имза) Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)

Башкаручы
(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))
_____________________________________
(башкаручының элемтә белешмәләре)